**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОМСОМОЛАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«18» августында 2025 ел Комсомол авылы №09

«Комсомол авыл җирлегенең 2025 елның
1 яртыеллыгына хисап үтәлеше проекты буенча
ачык тыңлаулар үткәрү турында»

Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, «Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Советының 2025 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турындагы хисап» карары проектын тикшерүдә катнашу өчен Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Башлыгы

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджетының 2025 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турында Отчет»карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга 2025 елның 20 августыннан да соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Ачык тыңлауларны уздыру көнен билгеләү:
3.1. 2025 елның 02 сентябрьдә көнне, сәгать 10.00 уздыру;
3.2. Уздыру көне – 1 көн;
3.3. Үткәрү урыны – ТР, Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге, Мәктеб урамы, 2А йорты (СДК бинасы).
3.4. Сораулар, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, Комсомол авылы, Мәктеб урамы, 2А йорт, (эш көннәрендә-8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр) бирергә була.
3.5. Ачык тыңлауларда катнашу хокукы белән гаризаларны бирү вакыты: 2025 елның 30 августында кадәр.

4.Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге башкарма комитетына «Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге бюджетының 2024 елның 1 ярты еллыгында үтәлеше турында хисап» карар проекты буенча ачык тыңлауларны бирелгән вакытта әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Комсомол авыл җирлеге Башлыгы О.В.Сурова

Совет Комсомольского сельского поселения